**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә мөгезле эре терлекләрдә йогышлы төерле дерматит авыруы таралу сәбәпле, имин булмаган вазгыять шартларында чикләү чаралары (карантин) кертү турында

Мөгезле эре терлекләрдә йогышлы төерле дерматит авыруы ачыклану һәм аның таралу куркынычы булу сәбәпле, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$, 17 статьялары, Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының «Мөгезле эре терлекләрдә йогышлы төерле дерматит авыруы таралуны булдырмауга һәм бетерүгә юнәлдерелгән профилактика, диагностика, дәвалау, чикләү һәм башка чараларны гамәлгә ашыру, карантин һәм башка чикләүләрне кертү һәм бетерү кагыйдәләрен раслау турында» 2017 елның 5 апрелендәге 166 номерлы боерыгы нигезендә **карар бирәм:**

1. Мөгезле эре терлекләрдә йогышлы төерле дерматит авыруы ачыклану сәбәпле, аны бетерү турында карар кабул ителгәнгә кадәр, әлеге Указның 2 нче пунктында билгеләнгән эпизоотия чыганаклары, имин булмаган пункт һәм куркыныч янаган зона территорияләрендә, аларның имин булмавы сәбәпле чикләү чаралары (карантин) кертергә.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

а) эпизоотия чыганакларын:

«Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Югары Чыршылы авыл җирлеге Югары Чыршылы авылындагы Ленин урамы 55 А номерлы йортта урнашкан шәхси йорт хуҗалыгы территориясен;

«Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Югары Чыршылы авыл җирлеге Югары Чыршылы авылындагы Ленин урамы 73 номерлы йортта урнашкан шәхси йорт хуҗалыгы территориясен;

б) «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Югары Чыршылы авыл җирлеге Югары Чыршылы авылы территориясе чикләрендә урнашкан имин булмаган пунктны;

в) имин булмаган пункт чикләреннән кимендә 10 километр радиустагы территория чикләрендә, Татарстан Республикасы Сарман районының Түбән Чыршылы авылын, Язикәү авылын, Ләке авылын, Ферма Сәүекле поселогын,

Петровский Завод авылын, Дуслык авылын, Пробуждение авылын, Мостафа авылын, Чукмарлы авылын, Юлтимер авылын, Шыгай авылын, Усай авылын, Янурыс авылын, Нарatасты авылын, Димитарлау авылын, Азалак авылын, Олы Нөркәй авылын, Күктау авылын, Зәй районының Зичәбаш авылын, Кабан Бастырык авылын, Дүртмунча авылын, Тукай районының Таулык авылын, Яңа Бүләк авылын, Күктәк-Мирсәет авылын, Иске Теләнче авылын, Кызыл Байрак авылын, Бай Бүләк авылын, Иске Дөреш авылын кертеп, куркыныч янаган зонаны.

3. Түбәндәгеләрне тыярга:

а) эпизоотия чыганакларында:

җитештерү (технология) операцияләрен башкаручы, шул исәптән авыруга бирешүчән терлекләрне караучы персоналдан, дәүләт ветеринария хезмәте белгечләре һәм авыру чыганагын бетерү өчен җәлеп ителгән персоналдан, эпизоотия чыганагы территориясендә яшәүче һәм (яки) вакытлыча яшәүче затлардан тыш, территориягә чит затларның керүен;

авыруга бирешүчән терлекләрне хуҗалык территориясенә кертүне (транспортта алып керүне) һәм аннан читкә чыгаруны (транспортта алып чыгуны);

авыруга бирешүчән терлекләрдән калган терлек азыгын чыгаруны;

авыру хайваннардан алынган сөт һәм сперманы читкә чыгаруны;

б) имин булмаган пунктта:

йогышлы төерле дерматит авыруына каршы вакцина ясалмаган терлекләрне транспортта кертүне;

авыруга бирешүчән терлекләрне куркыныч янаган зонадан транспортта чыгаруны (авыруга бирешүчән терлекләрне чалу өчен терлек чалу предприятиеләренә яисә шушы максатларда җиһазланган терлек чалу пунктларына транспортта чыгарудан тыш);

авыруга бирешүчән терлекләрне күчереп йөртү һәм туплау белән бәйле ярминкәләр, күргәзмәләр, башка чаралар үткәрүне;

в) куркыныч янаган зонада:

йогышлы дерматит авыруына каршы вакцинация узмаган терлекләрне транспортта кертүне;

авыруга бирешүчән терлекләрне куркыныч янаган зонадан транспортта чыгаруны (авыруга бирешүчән терлекләрне чалу өчен терлек чалу предприятиеләренә яисә шушы максатларда җиһазланган терлек чалу пунктларына транспортта чыгарудан тыш);

авыруга бирешүчән терлекләрне күчереп йөртү һәм туплау белән бәйле ярминкәләр, күргәзмәләр, башка чаралар үткәрүне.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының «Мөгезле эре терлекләрдә йогышлы төерле дерматит авыруы таралуны булдырмауга һәм бетерүгә юнәлдерелгән профилактика, диагностика, дәвалау,

чикләү һәм башка чараларны гамәлгә ашыру, карантин һәм башка чикләүләрне кертү һәм бетерү кагыйдәләрен раслау турында» 2017 елның 5 апрельдәге 166 номерлы боерыгында каралган чараларны эпизоотия чыганакларында, имин булмаган пунктта һәм куркыныч янау зонасында гамәлгә ашырырга.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә Татарстан Республикасы территориясендә мөгезле эре терлекләрнең йогышлы төерле дерматиты чыганакларын бетерү һәм аларның таралуын булдырмау буенча чаралар планын эшләргә һәм расларга.

6. Әлеге Указның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына йөкләргә.

7. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2022 ел, 25 гыйнвар
№ ПУ-55